ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

06 02 2023 г. № 105

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган аерым категория гражданнарга өстәмә социаль ярдәм күрсәтү чаралары турында» 2016 елның 4 маендагы 874 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, шулай ук мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган аерым категория гражданнарга өстәмә социаль ярдәм күрсәтү максатларында, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган аерым категория гражданнарга өстәмә социаль ярдәм күрсәтү чаралары турында» 2016 елның 4 маендагы 874 номерлы карары (алга таба – карар) белән расланган мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган аерым категория гражданнарга балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләвенең бер өлешенә өстәмә компенсация бирү тәртибенә түбәндәге үзгәреш кертергә:

2.1 пунктның җиденче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре һәм Түбән Кама муниципаль районы хәрби комиссарыннан алган белешмәләрдә әлеге абзацта күрсәтелгән ата-ана категориясенә карата мәгълүматлар булмаганда, мөрәҗәгать итүче икенче ата-ананы мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакыру турында чит шәһәр хәрби комиссариат органнары белешмәсен гаризасына өстәмә рәвештә терки.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А. Г. Мәхмүтовка йөкләргә.

---

Җитәкче Р.Ф. Булатов